Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
Иске Шөгер авыл җирлеге
Яңа Шөгер авылында гражданнар җыены
КАРАРЫ

2021 елның 20 ноябре № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2021 елның 20 ноябрендә 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Яңа Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

- балалар өчен спорт-уен инвентаре сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».

соравы буенча узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

Халык җыены беркетмәсе нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 185 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 114 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучылар бертавыштан «ӘЙЕ» позициясе өчен тавыш бирделәр.

Югарыда бәян ителгәннәрдән чыгып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлегенең Яңа Шөгер авылында гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге составына керүче Яңа Шөгер авылында гражданнар җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2022 елда үзара салым кертүгә Лениногорск муниципаль районы Иске Шөгер авыл җирлеге Яңа Шөгер авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчедән 300 сум күләмендә акча кертү һәм җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итү өчен алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрү белән килешәсезме:

1) җирлек халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял оештыру өчен шартлар тудыру;

- балалар өчен спорт-уен инвентаре сатып алу;

2) җирлек территориясен төзекләндерү буенча башка чаралар:

- МТЗ-82.1 тракторын карап тоту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү) карарын кабул ителгән, дип танырга.

3. Әлеге карарны Лениногорск районы, Яңа Шөгер авылы, Гагарин ур., 1/а адресы буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Лениногорск муниципаль районы
«Иске Шөгер авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Л.М.Шиһапова